**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

2020елның 8 сентябре 64 -РС номер

**КАРАР**

**Татарстан АССРның 100 еллыгы: тарих һәм заман**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башлыгы-Совет рәисе вазыйфаларын башкаручы Т.П. Борһановның«Татарстан АССРның 100 еллыгы: тарих һәм заман» дигән докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башлыгы-Совет рәисе вазыйфаларын башкаручы Т.П. Борһановның«Татарстан АССРның 100 еллыгы: тарих һәм заман» дигән докладын хупларга.

2. Район халкына районны торгызуда һәм үстерүдә, аның социаль-икътисади, фәнни-техник, рухи һәм мәдәни потенциалын ныгытуда актив катнашканнары өчен рәхмәт белдерергә.

3. Район һәм тулаем республика тарихының данлы битләрен һәм вакыйгаларын мәңгеләштерү буенча комплекслы эшне дәвам итәргә;

4. Үсеп килүче буын арасында республиканың казанышларын пропагандаларга;

5. Татар телен һәм мәдәниятен, Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен һәм мәдәниятләрен саклап калуга һәм үстерүгә ярдәм итәргә.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм интернет-телекоммуникация челтәрендәге Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, ветераннар һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**башлыгы-Совет рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Т.П.Борһанова**